**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**Карары**

Уразай авылы №53 25 февраль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү белән бәйле

Уразай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (28.09.2012 №28, 05.08.2013 №44, 22.10.2014 №85, 30.09.2015 №6, 15.11.2016 №47, 17.04.2018 №94, 03.09.2018 №108, 05.11.2019 №155-17, 17.11.2020 №12 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясен тозекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;».

1.2. 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:

«17) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

1.3. 20 статьяның 11 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм тозелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау кагыйдәләре проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә яисә рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, капиталь төзелеш объектларын төзүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт

бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турындагы карарларның проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен һәм мондый файдалануның башка төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирдән файдалануның расланган кагыйдәләре булмаганда һәм төзелеш корылмалары төзү турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә.».

1.4. 39 статьяныц 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы, чит дәүләт гражданлыгы булу яисә яшәү хокукы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясе гражданы йә чит ил гражданы территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ яисә чит ил гражданы булу хокукы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкача каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы;».

1.5. 44 статьяныц 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы, чит дәүләт гражданлыгы булу яисә яшәү хокукы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясе гражданы йә чит ил гражданы территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкача каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы чит ил гражданы;

1.6. 47 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле сигез абзац өстәргә:

«- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларныц файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра, шулай ук җирлек чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыра.»;

б) 47 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле сигез абзац өстәргә:

«- алкогольле, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 3 бүлек белән тулыландырырга:

«3. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Җирлекнең муниципаль контроль өлкәсендәге башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге җирлек Советы билгеләгән тәртиптә алып барыла;

2) җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан раслана торган типовой административ регламентлар нигезендә җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) федераль законнарда, законнарда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре әлеге органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә җирлек башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве уздыру өчен юлларга.

3.Дәүләт теркәве узганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасыныц рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча : http:/ aznakyevo.tatarstan.ru, Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шәрифуллина